Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«05» сентябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 5 сентябрендә узган: «2023 елда гражданнарның ъзара салым кертүдән трактор сатып алуга җыелган 532580 сум 00 тиен (биш йөз утыз ике мең биш йөз сиксән сум 00 тиен) күләмендә калган акчаларны БЕЛАРУС 82.1 тракторы өчен тагылмалы җиһазлар сатып алуга кулланырга ризамы» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде..

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 393 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 208 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 208 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

2. «2023 елда гражданнарның ъзара салым кертүдән трактор сатып алуга җыелган 532580 сум 00 тиен (биш йөз утыз ике мең биш йөз сиксән сум 00 тиен) күләмендә калган акчаларны БЕЛАРУС 82.1 тракторы өчен тагылмалы җиһазлар сатып алуга кулланырга ризамы» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Нурлат муниципаль районының рәсми http://nurlat.tatarstan.ru/ сайтында һәм Колбай-Мораса авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Ә. Насыйбуллин

Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин